**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

25 апрель 2018 ел №96

**Физик затларның милегенә налог турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 62 номерлы “ Физик затларның милегенә налог турында” карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2нче пунктның 3 нче пунктчасында 4нче абзацында “бер торак бина (торак йорт)” сүзләрен “бер торак йорт” сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар Рәсми порталында һәм Уставта каралган тәртип буенча авыл җирлегенең максус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

**Җирлек башлыгы Р.А. Вәлиев**